## «ТАТАР СҮЗЕ» IV халыкара нәфис сүз телевизион бәйгесен үткәрү турында НИГЕЗЛӘМӘ

### 1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. Әлеге Нигезләмә «ТАТАР СҮЗЕ» халыкара нәфис сүз телевизион бәйгесен (алга таба – Бәйге) оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.
1.2. Бәйге Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән уздырыла.
1.3. Бәйгене оештыручы (алга таба – Оештыручы) – «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыяте.
1.4. Оештыручының юридик адресы: 420095, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Ш. Усманов ур., 9 йорт.
1.5. Бәйгедә катнашу бушлай.

### 2. Бәйгенең максаты һәм бурычлары.

2.1. Бәйгенең максаты – туган телне, әдәби мирасыбызны пропагандалау, үстерү һәм саклау; классик язучыларның әсәрләрен популярлаштыру, милли әдәбиятка һәм мәдәнияткә кызыксыну уяту.
2.2. Бәйгенең бурычлары:

- сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үзләштерү;
- нәфис сүз аша Татарстан Республикасында, шулай ук Россия Федерациясе төбәкләрендә һәм чит илләрдә яшәүче милләттәшләрдә туган телгә кызыксыну уяту;
- классик язучылар һәм бүгенге заман язучылары иҗатын пропагандалау;
- башкару осталыгын камилләштерү өчен шартлар тудыру, талантлы башкаручыларның профессиональ сәхнәгә чыгуына ярдәм итү;
- телевизион кадрлар әзерләү.

### 3. Бәйгене үткәрү һәм аңа йомгак ясау тәртибе.

3.1. Бәйгедә Катнашучы Оештыручыга татар телендә яки үз туган телендә (чуваш, мари, мордва, удмурт) сәнгатьле итеп сөйләнгән әсәрне («Шигърият» яки «Проза») видеога төшереп, гариза белән бергә tatarsuze2024@yandex.ru электрон адресына яисә “Яндекс форма” https://shayantv.ru/tatarsuze_anketa тутырып җибәрә.

3.2. Катнашучыларның эшләре түбәндәге яшь категорияләре һәм номинацияләрдә бәяләнә:

а) 7 яшькә кадәр (7 яшьне дә кертеп);
ә) 8-13 яшь (8 һәм 13 яшьне дә кертеп);
б) 14-17 яшь(14 һәм 17 яшьне дә кертеп)
в) 18 яшь һәм өлкәнрәкләр;
г) үзе язган шигырьләрне сөйләүчеләр – 15 яшь һәм аннан өлкәнрәк катнашучылар;
д) иҗади гаилә;
е) профессионаллар*;
ж) Махсус номинация («Туган тел» номинациясе)**;

* Профессионаллар (профессиональ башкаручылар) булып атказанган, халык артистлары, шулай ук театр, кино, концерт оешмалары артистлары, дикторлар, нәфис сүз осталары, театраль уку йорты укытучылары һ.б. санала.

**Махсус номинациядә («Туган тел» номинациясе) чуваш, мари, мордва, удмурт халыклары вәкилләре катнаша ала. Катнашучылар классик һәм хәзерге заман язучылары әсәрләрен яисә үзе язган шигырьне үз туган телләрендә сөйли. Катнашучыларның яше чикләнмәгән. Гаризага Әсәрнең тәрҗемәсен дә беркетергә мөмкин.

3.3. Бәйге Номинацияләре (Әсәрләр):

а) Шигърият,

ә) Проза;

б) Махсус номинация («Туган тел» номинациясе).

3.4. Бәйгедә катнашу өчен түбәндәге гаризалар кабул ителә:

- татар халкының классик һәм хәзерге заман язучылары әсәрләре,
- үз туган телләрендә (чуваш, мари, мордва, удмурт) классик һәм хәзерге заман язучылары әсәрләре,
- Катнашучының үзе тарафыннан язылган шигырь.

3.5. Катнашучылар өч номинациягә дә гариза бирергә хокуклы. Номинациянең һәркайсына берешәр әсәр тәкъдим ителә. Һәр очракта гариза аерым рәсмиләштерелә.

3.6. Бәйге 2023 елның 03 июленнән алып 2024 елның 31 декабренә кадәр уздырыла.

3.7. Сайлап алу ике этапта уздырыла:

3.7.1. Беренче этап: Беренчел сайлап алу – 2023 елның 03 июленнән 2023 елның 30 ноябренә кадәр (ике датаны да кертеп).

Беренчел сайлап алу кысаларында Оештыру комитеты гаризалар кабул итә һәм аларның Нигезләмәгә туры килү-килмәвен тикшерә.

3.7.2. Икенче этап: Сайлап алу туры – 2023 елның 01 декабреннән 2024 елның 29 февраленә кадәр (ике датаны да кертеп).

Икенче этап барышында жюри әгъзалары Бәйгегә кабул ителгән эшләрне бәяли һәм ачык тавыш бирү юлы белән тиешле категорияләр һәм номинацияләр буенча Бәйгедә җиңүчеләрне билгели. Жюри карары беркетмә белән рәсмиләштерелә. Призлы урыннарны билгеләү Жюри әгъзалары бәяләве нигезендә башкарыла.

3.7.3. Өченче этап: 2024 елның 1 мартыннан 2024 елның 15 декабренә кадәр. Бәйге нәтиҗәләре буенча 15.12.2024 кадәр Гала-концерт оештырыла. Гала-концертны оештыру өчен өченче затлар җәлеп ителә ала. Гала-концертны үткәрү вакыты һәм урыны турындагы мәгълүматны Оештыручы сайтта алдан ук урнаштыра.

3.7.4. Җиңүчеләр, 2024 елның 01 нче мартыннан алып, Оештыручы тарафыннан өстәмә билгеләнгән вакытта «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖ нең «ШАЯН ТВ» каналы студиясенә чакырыла. Алар, үз чыгышларын тәкъдим итү максаты белән, телепрограмма яздыруда катнаша.

Оештыручы тарафыннан түбәндәгеләрне әзерләү планлаштырыла:

а) Бәйгегә багышланган 5 программа. Хронометраж: 15 минутка кадәр. Трансляция Оештыручының каналларында башкарылачак.

ә) Бер программа – Бәйгенең Җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы – Гала-концертның телевизион версиясе. Трансляция Оештыручының каналларында башкарылачак.

б) Хронометражы 5 минутка кадәр булган 37 программа Бәйгенең җиңүчеләре катнашында күрсәтелә. Трансляция Оештыручының каналларында башкарылачак.

в) Хронометражы 1 минутка кадәр булган 150 межпрограмма Бәйгенең катнашучылары катнашында күрсәтелә. Трансляция Оештыручының каналларында башкарылачак.

3.8. Бәйге нәтиҗәләре «Яңа Гасыр» ТРК» АҖ https://tnv.ru/ рәсми сайтында , «Майдан» https://maidan.tv/, телеканалының рәсми сайтында, социаль челтәрләрдә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында игълан ителәчәк.

3.9. Жюри тарафыннан билгеләнеп игълан ителгән нәтиҗәләр яңадан каралмый һәм үзгәртелми.

3.10. Балигъ булмаган зат җиңү яулаган очракта премия аның законлы вәкиленә бирелә.

3.11. Нигезләмәдә даталар якынча күрсәтелгән. Оештыручының карары буенча, Комиссия рәисе белән килештерелгәннән соң, алар үзгәрергә мөмкин. Оештыручының карары буенча, Комиссия рәисе белән килештерелгәннән соң, бәйге эше туктатылырга мөмкин. Оештыручының карары буенча, Комиссия рәисе белән килештерелгәннән соң, Бәйгенең Гала-концерты оештырылмаска мөмкин. Үзгәрешләр турында «Яңа Гасыр» ТРК» АҖ https://tnv.ru/ рәсми сайтында, “ШАЯН ТВ” телеканалының https://shayantv.ru/ рәсми сайтында, “Мәйдан” https://maidan.tv/ рәсми сайтында хәбәр ителәчәк.

## 4. Бәйге Эшләренә / Катнашучыларга таләпләр.

4.1. Бәйге Эшләренә таләпләр:
4.1.1. Бәйгедә Катнашучылар бәйге эшләрен барлык номинацияләр буенча да бирә ала.
4.1.2. Бәйге эше яттан сөйләнгән Шигърият яки Проза («Шигърият» яки «Проза») әсәрен бәян ителгән чыгышны видеога төшереп җибәрүдән гыйбарәт булырга тиеш.
4.1.3. Катнашучы чыгышының музыкаль яктан бизәлгән булуы хуплана.
4.1.4. Бәян ителә торган әдәби әсәр Катнашучының яшенә туры килергә тиеш.
4.1.5. Чыгыш ясау вакыты 5 (биш) минуттан артмаска тиеш.
4.2. Бәйгедә Катнашучыларга һәм аларның катнашуына карата таләпләр:
4.2.1. Бәйгедә катнашу буенча яшь чикләүләре юк. Бәйгедә РФ нең төрле төбәкләрендә һәм чит илләрдә яшәүчеләр катнаша ала.
4.2.2. Бәйгедә «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» («Яңа Гасыр» ТРК» АҖ) хезмәткәрләренә һәм аларның якын туганнарына катнашу рөхсәт ителми.
4.2.3. Бәйгедә алдагы елларда уздырылган «ТАТАР СҮЗЕ» халыкара нәфис сүз телевизион бәйгесендә җиңүчеләр янә катнаша ала, ләкин өч ел дәвамында кабат җиңү яулый алмый.
4.2.4. Бәйгедә катнашып, Катнашучы Оештыручыга әсәрне гади лицензия шартларында авторның аерым хокукларының гамәлдә булу вакыты дәвамында, куллану территориясен чикләмичә, РФ ГК 1270, 1317, 1324 маддәләрендә күрсәтелгән барлык ысуллар белән, авторны күрсәтеп, бушлай куллану хокукын тапшыра.
4.2.5. Бәйгедә катнашу автомат рәвештә Катнашучының Бәйге шартлары белән таныш булуын һәм алар белән тулысынча риза булуын күз алдында тота. Әлеге Нигезләмә Бәйгедә Катнашучыларның барысы өчен дә расланган һәм мәҗбүри булып тора.
4.2.6. Катнашучы әсәргә булган барлык хокукларның, шул исәптән авторлык хокукларының үзендә булуын гарантияли. Өченче затлар тарафыннан дәгъва булган очракта, Катнашучы килеп чыккан каршылыкларны үз хисабына мөстәкыйль рәвештә җайга салырга тиеш.

## 5. Гаризага һәм видеоматериалга таләпләр.

5.1. Гариза әлеге Нигезләмәдә күрсәтелгән Кушымта формасы буенча тапшырыла. Гаризаның татар телендә тутырылуы хуплана.

5.2 Видеога таләпләр:1920*1080, 16.9 (горизонталь рәвештә), mpg, mpeg2 яки mpeg4 (H264) форматында.

## 6. Оештыручының бурычлары һәм хокуклары.

6.1. Оештыручының бурычлары:

- Бәйгенең җитәкчесен билгеләү, оештыру комитетын төзү, аның составына оештыру комитеты рәисе, оештыру комитеты әгъзалары (14 кеше) керә;
- Бәйгене үткәрүне оештыру;
- Бәйгенең Жюри составын формалаштыру;
- Җиңүчеләрне бүләкләү тантанасын оештыру;
- Бәйгенең Гала-концертын үткәрүне оештыру.

6.2. Оештыручының хокуклары:

- Бәйгенең уздырылу вакытын үзгәртү;

- Бәйгедә Катнашучылар тарафыннан тәкъдим ителә торган мәгълүматларның ышанычлы булуын тикшерү;
- Бәйгедә җиңүчеләр турындагы мәгълүматны һәм аларның чыгышларын үз теләге буенча барлык массакүләм мәгълүмат чараларында һәм социаль челтәрләрдә урнаштыру.

6.3. Оештыру комитетына түләү каралган.

## 7. Оештыру комитетының бурычлары һәм хокуклары

**7.1. Оештыру комитетының бурычлары:**

- Бәйгене үткәрүнең билгеләнгән тәртибен саклауны тәэмин итү;
- Барлык Катнашучылар өчен бертигез шартлар булдыру;
- Бәйгедә катнашу өчен Гаризалар кабул итү, Гаризаларның, Эшләрнең әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү;
- Тәкъдим ителгән Гаризаның әлеге Нигезләмә таләпләренә туры килмәү очраклары ачыкланса, Гаризаны теләсә кайсы этапта кире кагу;
- Катнашучылар турындагы мәгълүматларның конфиденциальлеген саклауны тәэмин итү;
- Гаризаларның, Бәйгедә катнашу өчен җибәрелгән Эшләрнең әлеге Нигезләмәдә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерү;
- Бәйгенең йомгаклау документларын рәсмиләштерү;
- ММЧ белән эшләү, PR-кампанияләр, матбугат конференцияләре оештыру;
- Комиссиягә һәм массакүләм мәгълүмат чараларына Бәйгенең барышы турында оператив мәгълүмат бирү;
- Бәйгегә багышланган телепрограммалар яздыруда катнашу өчен Бәйге җиңүчеләрен чакыру;
- Җиңүчеләрне бүләкләү тантанасын оештыру;
- Бәйгенең Гала-концертын үткәрүне оештыру.

**7.2. Оештыру комитетының хокуклары**:

- Бәйгедә Катнашучылар тарафыннан тәкъдим ителә торган мәгълүматларның ышанычлы булуын тикшерү;
- Тәкъдим ителгән Гаризаның Бәйге шартларына туры килмәү очраклары ачыкланса, Гаризаны кире кагу;

## 8. Бәйгенең жюри составы һәм җиңүчеләрне сайлап алу тәртибе.

8.1. Бәйгенең Катнашучылары жюри тарафыннан 5 баллы система буенча бәяләнә. Рәис белән берлектә профессиональ жюри (7 кешедән тора): югары һөнәри белеме булган Татарстан Республикасының, Россия Федерациясенең, якын һәм ерак чит илнең танылган артистлары, педагоглар, шагыйрьләр, продюсерлар, режиссерлар, журналистлар, иганәчеләр, иҗтимагый-сәяси эшлеклеләр, дәүләт хакимияте органнары вәкилләре һәм башка иҗади интеллигенция һәм эшлекле даирә вәкилләре арасыннан төзелә һәм раслана.
8.2. Жюри тарафыннан Катнашучыларның башкару осталыгы (актерлык осталыгы, дикция һ.б.), видеоязманың сыйфаты, шулай ук чыгышның (шул исәптән костюмның, реквизитның, музыкаль бизәлешнең) оригиналь булуы бәяләнә.
8.3. Жюри карары соңгы дип санала һәм кабаттан тикшерелми.
8.4. Жюриның хокуклары:

- Катнашучылар арасында призлы урыннарны бүлеп бирү;
- барлык призлы урыннарны да бирмәү.

8.5. Оештыручы тарафыннан чакырылган Жюри әгъзаларына («Яңа Гасыр «ТРК» АҖ хезмәткәрләреннән тыш) түләү каралган

**9. Җиңүчеләрне бүләкләү.**

9.1. Бәйгедә җиңүчеләргә акчалата премияләр Бәйгегә бирелгән акча исәбеннән түләнә.

9.2.Оешмалар һәм предприятиеләр Бәйгедә Катнашучыларга махсус бүләкләр һәм премияләр бирергә мөмкин.

9.3. Номинацияләрдә түбәндәге категорияләр буенча премия каралган:

9.3.1. “Шигърият” һәм “Проза” номинациясендә һәр категория өчен 3 (өч) премия карала (әлеге Нигезләмәнең 3.2. пунктындагы «а» – «в» пунктчалары):

**1. 7 яшькә кадәрге (7 яшьне дә кертеп) катнашучылар арасында: (“Шигърият” һәм “Проза”)**

I урын – 28 750 (егерме сигез мең җиде йөз илле) сум, һәр номинациядә;
II урын – 23 000 (егерме өч мең) сум, һәр номинациядә;
III урын – 17 250 (унҗиде мең ике йөз илле) сум, һәр номинациядә.

**2. 8-13 яшькә кадәрге (8 һәм 13 яшьне дә кертеп) катнашучылар арасында: (“Шигърият” һәм “Проза”)**

I урын –34 500 (утыз дүрт мең биш йөз) сум, һәр номинациядә;
II урын –28 750 (егерме сигез мең җиде йөз илле) сум, һәр номинациядә;
III урын –23 000 (егерме өч мең)сум, һәр номинациядә.

**3. 14-17 яшь(14 һәм 17 яшьне дә кертеп) катнашучылар арасында: (“Шигърият” һәм “Проза”)**

I урын – 40 250 (кырык мең ике йөз илле) сум, һәр номинациядә;
II урын –34 500 (утыз дүрт мең биш йөз)сум, һәр номинациядә;
III урын –28 750 (егерме сигез мең җиде йөз илле) сум, һәр номинациядә.

**4. 18 яшь һәм өлкәнрәк катнашучылар арасында: (“Шигърият” һәм “Проза”)**

I урын – 57 500 (илле җиде мең биш йөз) сум, һәр номинациядә;
II урын – 51 750 (илле бер мең җиде йөз илле) сум, һәр номинациядә;
III урын – 40 250 (кырык мең ике йөз илле) сум, һәр номинациядә.

**5. Үзе язган шигырьләрне сөйләүчеләр – 15 яшь һәм аннан өлкәнрәк катнашучылар. “Шигърият”** (әлеге Нигезләмәнең 3.2. пунктындагы «г» пунктчасы):

I урын – 57 500 (илле җиде мең биш йөз) сум;
II урын – 46 000 (кырык алты мең) сум;
III урын – 40 250 (кырык мең ике йөз илле) сум.

9.3.2. **Иҗади гаилә** категориясендә (әлеге Нигезләмәнең 3.2. пунктындагы «д» пунктчасы) өчен, номинацияләргә бүлмичә, барлыгы 3 (өч) премия карала:

I урын – 92 000 (туксан ике мең) сум;
II урын – 80 500 (сиксән мең биш йөз) сум;
III урын – 57 500 (илле җиде мең биш йөз) сум.

9.3.3. **Профессиональ катнашучылар** категориясендә (әлеге Нигезләмәнең 3.2. пунктындагы «е» пунктчасы) өчен, номинацияләргә бүлмичә, барлыгы 3 (өч) премия карала:

I урын – 92 000 (туксан ике мең) сум сум;
II урын – 80 500 (сиксән мең биш йөз) сум;
III урын – 57 500 (илле җиде мең биш йөз) сум.

**9.3.4. Махсус номинация («Туган тел» номинациясе)** (әлеге Нигезләмәнең 3.2. пунктындагы «ж» пунктчасы) өчен, номинацияләргә бүлмичә, барлыгы 4 (дүрт) премия карала:
Җиңүче – 34 500 (утыз дүрт мең биш йөз) сум;
Җиңүче– 34 500 (утыз дүрт мең биш йөз) сум;
Җиңүче– 34 500 (утыз дүрт мең биш йөз) сум;
Җиңүче – 34 500 (утыз дүрт мең биш йөз) сум.

**НӘТИҖӘДӘ: 1 558 250 (бер миллион биш йөз илле сигез мең ике йөз илле) сум.**

9.4. Җиңүчеләргә акчалата премияләр затлар тарафыннан бирелгән банк реквизитлары буенча күчерелә. Акчалата премияләр түләгән вакытта салым агенты буларак, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыяте («Яңа Гасыр» ТРК» АҖ) физик затлар кеременнән 13% күләмендә салым тотып кала.
9.5. РФ ГК 217 маддәсенең 28 пункты һәм РФ ГК 224 маддәсенең 2 пункты нигезендә, 4 000 (дүрт мең) сумнан артык бәяле премиядән җиңүче (салым түләүче) әлеге маддәләрдә каралган барлык салымнарны түләргә тиеш. Бүләк алынганнан бирле, бүләккә салым түләү өчен җаваплылык җиңүчегә йөкләнә.
9.6. Бүләкләргә милек хокукы призны тапшырган вакыттан җиңүчегә күчә. Бүләк тапшырылганнан соң, бүләкнең очраклы рәвештә юкка чыгу яки югалту куркынычы җиңүчегә йөкләнә.

## 10. Башка шартлар.

10.1. Әлеге Нигезләмәдә күрсәтелмәгән мәсьәләләр, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе белән килештерелеп, Оештыручы тарафыннан Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына нигезләнеп хәл ителә.
10.2. Бәйге турында тулы мәгълүмат «Яңа Гасыр «ТРК» АҖ («Яңа Гасыр» ТРК» АҖ) телеканалларының барлык интернет ресурсларында: https://tnv.ru/, https://shayantv.ru/ сайтларында, Вконтакте социаль челтәрендәге https://vk.com/tatarstan_tnv/, https://vk.com/shayantv төркемнәрендә, https://youtube.com/ШАЯНТВ/, https://youtube.com/ТНВ/ YouTube каналларында, https://rutube.ru/channel/23486483/, https://rutube.ru/channel/25096583 Rutube каналларында, “Мәйдан” телеканалының https://maidan.tv/ рәсми сайтында Вконтакте социаль челтәрендәге https://vk.com/clubmaidan төркемендә, https://youtube.com/MAIDAN TV/ YouTube каналында, https://rutube.ru/channel/24115502/ Rutube каналында урнаштырылачак.
10.3. Бәйгедә катнашу Катнашучының 2006 елның 27 июлендә кабул ителгән 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларын танышу, мәгълүмати һәм реклама максатларында кулланырга ризалык бирүен күз алдында тота. Бәйгедә катнашканнан соң, Катнашучылар аларның исемнәре, фамилияләре, фотолары, интервьюлары һәм башка материаллары, шул исәптән электрон почта аша җибәрелгән хат текстлары, Оештыручы тарафыннан чикләнмәгән территориядә һәм чикләнмәгән вакытка моның өчен нинди дә булса бүләк түләмичә һәм өстәмә рөхсәт алмыйча кулланылырга мөмкинлеге белән килешәләр. Бәйгедә катнашу катнашучының Бәйгедә катнашу, Бәйге нәтиҗәләрен билгеләү, приз алу, оештыручының реклама тәкъдимнәрен алу, шулай ук Бәйгедә катнашучыларның шәхси мәгълүматларын оештыручының конфиденциальлек турында йөкләмә алган партнер оешмаларына тапшыру максатыннан, аның шәхси мәгълүматларын Оештыручы тарафыннан закон белән тыелмаган теләсә нинди ысул белән эшкәртүгә ризалыгын аңлата.

10.4. . Бәйгедә катнашу Катнашучының 2006 елның 27 июлендә кабул ителгән 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларын танышу, мәгълүмати һәм реклама максатларында кулланырга ризалык бирүен күз алдында тота. Шәхси мәгълүматлар Бәйгенең уздырылу вакыты дәвамында, шулай ук Бәйге тәмамлаганнан соң да, мондый ризалыкны кире алганчы кулланыла. Катнашучылар барлык массакүләм мәгълүмат чараларында, социаль челтәрләрдә, шул исәптән «Яңа Гасыр» ТРК» АҖ телеканалларында, "Мәйдан" телеканалында, әлеге каналларның YouTube, Rutube каналларында, социаль челтәрләрдә Бәйгедә катнашу турында интервью бирергә, шулай ук видео һәм график материаллар әзерләүдә нинди дә булса бүләкләрсез (бушка) катнашырга ризалаша.
10.5. Бәйгедә катнашып, Катнашучы шуның белән РФ Гражданлык кодексында каралган барлык ысуллар белән, әлеге Нигезләмәдә каралган максатларда, куллану вакыты һәм территориясе чикләнмичә, Оештыручы тарафыннан гади (аерым булмаган) лицензия шартларында аудиоязманы түләүсез куллануга ризалыгын белдерә.
10.6. Бәйгене Оештыручы һәм/яки аның хокук варислары аудиоязмалар куллану өчен нинди дә булса юридик яки физик затларга, шулай ук авторлык һәм тугандаш хокукларны коллектив идарә итүче оешмаларга түләүләр өчен җаваплылыктан азат ителгән.
10.7. Бәйге җиңүчесе Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган барлык салымнарны һәм җыемнарны, Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган тәртиптә, Бәйгедә катнашкан өчен бүләкләү рәвешендә керемнәр алуга бәйле рәвештә түләү бурычын башкара.
10.8. Оештыручы үз йөкләмәләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен, шулай ук Бәйгедә катнашу белән бәйле Катнашучыларның турыдан-туры, турыдан-туры булмаган, аерым югалтулары, телекоммуникация челтәрләрендәге өзеклекләр, зарарлы программалар гамәлләре, шулай ук көтелмәгән көч шартлары нәтиҗәсе өчен җаваплы түгел. Оештыручы мондый очракларда Бәйгедә катнашучыларның югалтуларын капларга тиеш түгел.
10.9. Әгәр Катнашучы яки катнашучы мәнфәгатьләрендә эш итүче теләсә кайсы башка зат Бәйге барышында Бәйгенең барышына, Бәйге нәтиҗәләренә йогынты ясарга тырыша дигән шикләр барлыкка килсә, Оештыручы Катнашучыны Бәйгенең теләсә кайсы этабында катнашудан читләштерергә хокуклы.
10.11. Әгәр Катнашучының һәм/яки анкетаның һәм/яки видеоязманың Бәйге шартларына туры килмәве ачыкланса, Оештыручы Катнашучыны Бәйгедә катнашудан читләштерү хокукына ия.
10.12. Өстәмә мәгълүматны tatarsuze2024@yandex.ru электрон почтасына язып белеп була.

*«ТАТАР СҮЗЕ» халыкара нәфис*
*сүз телевизион бәйгесен үткәрү турындагы*
**Нигезләмәгә Кушымта**

**Катнашучының анкетасы**

Гаризаны электрон форматта тутырырга мөмкин https://shayantv.ru/tatarsuze_anketa

| | |
|---|---|
| Катнашучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туган елы, кыскача биография, шәхси телефон номеры | |
| Белем дәрәҗәсе (уку йорты, тәмамлау елы), эш яки уку урыны<br>Артист һ.б. исем бирелү турында документлар | |
| Номинация атамасы, яшь категориясе | |
| Әсәр атамасы<br><br>Авторның фамилиясе, исеме | |

Бәйге шартлары белән килешүне һәм шәхси мәгълүматларымны *һәм балигъ булмаган катнашучының шәхси мәгълүматларын (булган очракта)* «Яңа Гасыр «ТРК» АҖнә эшкәртүгә һәм таратуга ризалык бирүемне раслыйм.
Тапшырылган мәгълүматларның дөрелеген гарантиялим.
*Бәйгегә тәкъдим ителгән, югарыда күрсәтелгән Әсәрнең авторы чыннан да үзем булуын дәлиллим (булган очракта)*

«___»_________________________2023 ел.          Катнашучының имзасы________________

Дата ____________

Катнашучының имзасы:___________________________ /______________________________/
*ФИО*